КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 декабрь г.Казань № 1047

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2017 ел, 16 март, 147 нче карары белән расланган 2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2017 ел, 16 март, 147 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 7 июнь, 352 нче, 2017 ел, 17 октябрь, 793 нче һәм 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы» бүлегенең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «8. | Хезмәткә яраклы яшьтәге авыл халкының эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсе, процент | квартал | 80,3 | 81,9 | 81 | 81,5 | 81,9 | 80 | 84 | 84»; |

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» бүлегенең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «6. | Тулаем төбәк продуктында төп капиталга инвестицияләр өлеше, процент | квартал | 33,8 | 33,9 | 17,0 | 20,0 | 24,0 | 24,5 | 24,5 | 25,0»; |

«Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» бүлегенең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1. | Яшәү дәрәҗәсе (типик гаилә әгъзасының минималь куллану бюджетына карата халыкның җан башына акчалата керемнәре), бер тапкыр | еллык | 2,41 | 2,37 | X | X | X | ≥ 2,0 | ≥ 2,1 | ≥ 2,2». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин